**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

Постановление Карар

2019 ел «21» гыйнвар №14

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында күмү һәм җирләү эше буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196нчы "Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында” карары нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “2019 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында” 2019 елның 24 гыйнварындагы 32 номерлы карары нигезендә, Әтнә муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.2019 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында, 1нче, 2нче кушымта нигезендә, күмү һәм җирләү эше буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 5946,47 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Башкарма комитетының «Күмү һәм җирләү эше буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр кыйммәтен раслау турындагы" 2018 елның 29 гыйнварындагы 15/1 номерлы карары 2019 елның 1 февраленнән үз көчен югалтты дип санарга.

3. Әлеге карарны масакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Әтнә районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын вакытлыча үтәүче

А.Ф.Каюмов

Кушымта № 1

Әтнә муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 21 гыйнварындагы 14 нче номерлы карарына

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында
2019 елның 1 февраленнән җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе

| **Хезмәтләрнең исеме** | **Хезмәтләрнең бәясе (сумнарда)** |
|---|---|
| 1.Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2.Гробны, җирләү өчен кирәкле башка предметларны тәкъдим итү һәм китерү | 3937-43 |
| 3.Зиратка үлгән кешенең мәетен китерү | 475-51 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм җирләү) | 1533-53 |
| **Барлыгы** | **5946-47** |

Кушымта № 2

Әтнә муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 21 гыйнварындагы 14 нче номерлы карарына

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында
2019 елның 1 февраленнән җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе

| **Хезмәтләрнең исеме** | **Хезмәтләрнең бәясе (сумнарда)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Тәнне каплау | 213-97 |
| 3. Гробны, җирләү өчен кирәкле башка предметларны тәкъдим итү һәм китерү | 3723-46 |
| 4. Зиратка үлгән кешенең мәетен китерү | 475-51 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм җирләү) | 1533-53 |
| **Барлыгы** | **5946-47** |